КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 июль г.Казань № 610

Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларының үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм коммерциягә карамаган оешмаларның үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү өчен Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларының үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 20 июль, 610 нчы
карары белән расланды

Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында
Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның
үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән
тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга
Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия
(дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) (алга таба – оешма, субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Субсидия коммерциягә карамаган оешмаларга тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре:

хезмәт өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

мөлкәти хокукларны, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу;

командировка чыгымнары;

физик һәм юридик затлар хезмәтләре, шул исәптән элемтә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану, техник ярдәм күрсәтү хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, иминләштерү, коммуналь хезмәтләр, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве, мөлкәтне һәм транспорт чараларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре һәм алар белән бәйле башка хезмәтләр өчен түләү;

бәясе 1 берәмлек өчен 4 мең сумнан да артмаган, алга таба сату өчен билгеләнмәгән бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу (әзерләү);

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән каралган максатларны тормышка ашыру өчен төп чараларны һәм матди запасларны сатып алу.

5. Субсидия түбәндәге таләпләргә җавап бирә торган коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – субсидия алучылар) бирелә:

коммерциягә карамаган оешма Татарстан Республикасы территориясендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән юридик зат булу;

коммерциягә карамаган оешма субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1есенә:

салымнар, җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты алдында башка үз вакытында түләнмәгән бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, коммерциягә карамаган оешманың эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган булу.

6. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешма Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия бирүгә заявка;

коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр кертү турындагы документлар күчермәләре;

субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турында мәгълүмат;

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 5 нче пункты белән каралган шартларга туры килүен раслый торган документлар.

7. Коммерциягә карамаган оешма үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

коммерциягә карамаган оешманы юридик зат буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен (Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсен);

салым органында коммерциягә карамаган оешманы исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу пунктның икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Субсидияләр бирүгә заявкаларны кабул итү турында белдерү Министрлыкның «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://mincult.tatarstan.ru) бастырып чыгарыла. Белдерүдә Министрлыкның документларны кабул итүне гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе күрсәтелә.

Коммерциягә карамаган оешмалардан субсидияләр бирүгә заявкалар бирү вакыты белдерү басылып чыккан көннән соң 10 календарь көн тәшкил итә.

9. Министрлык:

субсидия бирү турындагы заявкаларны алар кергән көнне теркәүгә ала;

бу Тәртипнең 8 нче пункты белән билгеләнгән заявкалар бирү вакыты тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә бу Тәртипнең 11 нче пункты нигезендә субсидия бирүгә заявкаларны бәяли һәм субсидия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә коммерциягә карамаган оешма белән субсидия бирү турында килешү төзи.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 6 нчы пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

Министрлык субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

11. Субсидия бирүгә заявкаларны бәяләү критерийлары түбәндәгеләр була:

коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегенең төп юнәлешләре бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән һәм тормышка ашыру өчен субсидия бирелә торган максатларга туры килү (туры килгән очракта – 1 балл);

үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен матди-техник һәм кадрлар ресурслары булу (булган очракта – 1 балл);

зур бөтенроссия һәм халыкара чараларны үткәрү тәҗрибәсе булу (бер елга кадәр тәҗрибә – 1 балл; бер елдан өч елга кадәр – 2 балл; өч елдан дүрт елга кадәр – 3 балл; дүрт елдан алты елга кадәр – 4 балл; алты елдан артыграк – 5 балл).

Субсидия заявкасы иң күп балл җыйган коммерциягә карамаган оешмага бирелә.

12. Бирелә торган субсидия күләме (С), шундый ук товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_{фот} + З_{налоги} + З_{приобрет} + З_{ком} + З_{усл} + З_{сувен} + З_{ОСиМЗ},$$

монда:

$З_{фот}$ – хезмәт өчен түләүгә чыгымнар;

$З_{налоги}$ – Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү чыгымнары;

$З_{приобрет}$ – мөлкәти хокукларны, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алуга чыгымнар;

$З_{ком}$ – командировка чыгымнары;

$З_{усл}$ – физик һәм юридик затлар хезмәтләре, шул исәптән элемтә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалану, техник ярдәм күрсәтү хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, иминләштерү, коммуналь хезмәтләр, мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве, мөлкәтне һәм транспорт чараларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү хезмәтләре һәм алар белән бәйле башка хезмәтләр өчен түләү чыгымнары;

$З_{сувен}$ – бәясе 1 берәмлек өчен 4 мең сумнан да артмаган, алга таба сату өчен билгеләнмәгән бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу (әзерләү) чыгымнары;

$З_{ОСиМЗ}$ – бу Тәртипнең 2 нче пункты белән каралган максатларны тормышка ашыру өчен төп чараларны һәм матди запасларны сатып алуга чыгымнар.

13. Субсидияләр бирү Министрлык һәм субсидияләр алучылар арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә торган субсидия бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешүдә субсидияләр күләме, аның максатчан билгеләнеше, үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү өчен Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнар төрләре, субсидия күчерү тәртибе һәм вакытлары, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисаплылык бирү формалары һәм вакытлары, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары һәм тәртибе, субсидия алучының Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю (югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш), шулай ук субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең һәм төзелә торган килешүнең шартларын үтәү карала.

14. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында бер стильдә үткәрелгән чаралар саны тора.

15. Министрлык субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 20 көн эчендә субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына субсидия күчерә.

16. Субсидияләр алучылар субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

17. Субсидияләр алучылар квартал саен Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турындагы хисапны;

хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипнең 2 нче кушымтасында бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапны.

IV квартал өчен хисаплар субсидия биргән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр бирелә.

18. Субсидияләр субсидияләр алучылар тарафыннан түбәндәге очракларда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән шартларны бозу;

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә һәм документлар тапшырганда;

бу Тәртипнең 17 нче пункты белән каралган хисаплылыкны билгеләнгән вакытларда тапшырмаганда;

оешма субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә;

19. Субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре субсидия алучы тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемөнә кире кайтарылырга тиеш.

20. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 18 һәм 19 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

21. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

22. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

20___ елның «___»________ енә(ына)

______________________________________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме)

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) торган чыгымнар турында хисабы

| Т/с | Субсидияләрне тоту юнәлешләре | План, сум | Факт, сум | Чыгымнарны үтәү проценты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | |
| 2. | | | | |
| | Барлыгы | | | |

Коммерциягә карамаган оешма
җитәкчесе ___________________ ______________________ ________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (имзасы)

20___ ел, «___»___________

Үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

20___ елның «___»________ енә(ына)

______________________________________________
(коммерциягә карамаган оешманың исеме)

үткәрелә торган чараларның стиль бердәмлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүенең 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында чараларның җаваплы башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген оештыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидия (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисабы

| Т/с | Нәтиҗәнең исеме | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылуның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| | Барлыгы | | | | |

Коммерциягә карамаган оешма
җитәкчесе ___________________ ______________________ ________________
(вазыйфасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда)) (имзасы)

20___ ел, «___»___________

_____________________________